Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге Иске Чаллы авылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ

«12» ноябрь 2024 ел № 8

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Иске Чаллы авыл җирлеге Иске Чаллы авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. 2025 елда Нурлат муниципаль районының Иске Чаллы авыл җирлеге Иске Чаллы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту.

Халык җыенында рәислек итүче Г.В. Герасимов

Иске Чаллы авыл җирлеге башлыгы вазыйфаларын башкаручы Г.В. Герасимов